# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫИСКЕ ИБРАИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

10.02.2015 ел

№ 7

Иске Ибрай авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм кулану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү һәм үткәрү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьяларына, Татарстан Республикасы Законының 18 статьясына ярашлы 24.03.2004 № 23-ТРЗ «Җирле референдум турында», «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Ибрай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 15 статьясы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Ибрай авыл җирлеге Советы карары:

1. Иске Ибрай авыл җирлеге Советы инициативасын хупларга һәм Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Ибрай авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдумны 2015 елның 29 мартында якшәмбе көнне 7.00 сәгатьтән 20.00 сәгатькә кадәр билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Сез 2015 елда Иске Ибрай авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, шулай ук Иске Ибрай авыл җирлеге территориясендә теркәлмәгән, әмма милекләре булган һәр кешедән 200 сум, I һәм II төркем инвалидларга һәм Бөек Ватан сугышы ветераннарына 100 (йөз) сумм күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә ризамы:

Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:

1. Торак пунктларны төзекләндерү һәм халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:

яр буе урамында су башнясын тулыландыру, күтәрү, урнаштыру, яр буе урамындагы су башнясыннан Татарстан урамындагы сууткәргечкә кадәр сууткәргеч системасын божралау, озынлыгы 600 метр-269 200 сум.

2. Иске Ибрай авылының Фруктовая урамындагы зиратларны төзекләндерү-1000 сум.

3. Юлларны карап тоту һәм ремонтлау, Иске Ибрай авылының Үзәк урамындагы юлны тигезләү-1000 сум.

4. Иске Ибрай авылыннан чүп-чар чыгару-1000 сум.

5. Иске Ибрай авылында хуҗасыз этләр аулау 1000 сум.

6.Урамяктыртуны ремонтлау Иске Ибрай авылының Үзәк урамындагы лампаларны алыштыру-1000 сум.

ӘЙЕ, ЮК.

3.Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Ибрай авыл җирлеге территориясе чикләрендә референдум даирәсен билгеләргә.

4.Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Ибрай авыл башкарма комитетына 18 яшькә җиткән сайлаучылар исемлеген төзергә һәм Иске Ибрай авыл җирлегенең участок сайлау комиссияләренә раслау өчен тапшырырга.

5.Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Ибрай авыл җирлегенең участок сайлау комиссияләренә гамәлдәге законнарга ярашлы рәвештә Иске Ибрай авыл җирлеге территориясендә референдум үткәрүне оештырырга.

6.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http://Aksubayevo.tatarstan.ru. Һәм түбәндәге адрес буенча мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә:

- ТР, Аксубай районы, Иске Ибрай авылы, Кооператив урамы, 2 нче йорт;

Аксубай муниципаль районы
Иске Ибрай авыл җирлеге башлыгы,
Совет Рәисе

Х.Х.Әхмәтсафин